**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «03» февраленнән № 45

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында"гы 2019 елның 15 ноябрендәге 272 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контроль чараларын үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын юкка чыгару турында» 8.10.2020 ел, № 1631 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2009 ел, 15 ноябрь, 272 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны хисаплап чыгару Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлегендәге 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» (алга таба текс буенча - методик рекомендацияләр) 2009 ел, 2 июль, 546 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә

муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында (алга таба - мәктәпкәчә белем бирү оешмасы) тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны формалаштыру механизмын билгели

1.2. 2.6 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"закон нигезендә кабул ителә торган туклану нормалары;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:// pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов